Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

DOI: 10.26907/2311-2042-2022-18-1-207-216

# LATEST EVENTS IN THE FIRST HALF OF 2022

On February 11, 2022, the Institute of History named after Sh. Marjani, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, held an international round table on the “Prospects for the Study of Ottoman Sources on Medieval History of the Tatars”. The event was attended by such well-known historians as I. Zaitsev (Moscow), Ilyas Kemaloglu (Istanbul, Turkey), I. Mirgaliev, D. Iskhakov, I. Mustakimov, I. Izmailov, M. Gibatdinov and A. Zabirov (Kazan). The issues, raised by the speakers, aroused great interest and response on the part of the round table participants, the event went really well (for more details, see the official website: http://ft.antat.ru/uploads/805046256cf596e392-FT-2022-1_(1)-184-190.pd).

---

On February 18, the International Scientific and Methodological Online Seminar “Improving Language Teaching Methods: A Platform for the Exchange of Progressive Practices” was held at the Institute of Philology and Intercultural Communication (IPIC) at Kazan Federal University (KFU); this year, it has been organized for the sixth time.

The organizers of this International Scientific and Methodological Online Seminar were the Higher School of National Culture and Education named after Gabdulla Tukay and the Institute of Kayum Nasyri IPIC KFU. The seminar was organized with the participation of scientists from the Ege University (Republic of Turkey), Freiburg University (Germany), Azerbaijan State Pedagogical University (Republic of Azerbaijan), Eurasian National Universitynamed after L. N. Gumilyov, Kazakh National Pedagogical University named after Abay (Republic of Kazakhstan), National University of Uzbekistan named after Mirzo Ulugbek (Republic of Uzbekistan), Gorno-Altai State University, Bashkir State Pedagogical University named after M. Akmulla, Chuvash State University named after I. N. Ulyanov and other universities. To take part in the seminar, more than 120 participants sent their applications: teachers of universities and colleges, teachers of native and foreign languages of general educational institutions, graduate students, masters and undergraduates involved in the problems of teaching and learning languages, and topical problems of Turkic studies, from Russia, Turkey, China, Azerbaijan, Kazakhstan, Turkmenistan and Uzbekistan.

The speakers shared their advanced pedagogical experience by clearly demonstrating solutions to the methodological problems of language learning and Turkic education in universities and educational institutions and by answering questions asked by the participants of the seminar (for more details, see the website of the Kazan Federal University IFMK: https://kpfu.ru/philology-culture/vi-mezhdunarodnyj-nauchno-metodicheskij-online.html).

The Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, presented a three-volume publication dedicated to the life and work of the Tatar poet Gabdulla Tukay.

According to the Candidate of Philology Marcel Ibragimov, the publication is distinguished by a variety of documentary material. "There are archival sources, letters, diaries, memoirs, materials from newspapers and magazines and official papers of various organizations. All these make it possible to see Tukay's life and his creative path in connection with the national and cultural environment of that time," the scientist said (for more details, see the website tatar-inform.ru: https://www.tatar-inform.ru/news/iyali-predstavil-novyi-trextomnik-o-tukae-5848011).

---

On February 21, the Institute of Philology and Intercultural Communication hosted the Thirteenth International Research and Practice Conference "Turkic Linguoculturology: Problems and Prospects". The event was dedicated to the International Mother Language Day. The conference was held in a hybrid form. It was attended by students, masters and schoolchildren from Tatarstan, Bashkortostan, Tyumen region, Yakutia, Moscow, as well as from Kazakhstan, Turkmenistan, Uzbekistan, China, Karelia and Syria.

Within the framework of the conference, several scientific sessions and round tables were organized. The most interesting of them was the event "Studying the Creative Heritage of Hadi Taktash at School: The Present State and Prospects", organized by Milyausha Khabutdinova, a candidate of philology, associate professor in the Department of Tatar Literature, with the participation of the Tatar language teachers. At the event, the guests of honor were Masguda Shamsutdinova, a composer, the author of the H. Taktash oratorio "The Tragedy of the Sons of the Earth" and the People's Artist of Tatarstan Gulzada Safiullina. The participants of the round table discussed Taktash's work and music, the symphonism of Taktash's poetry, the originality of the Tatar language and the relevance of the great poet's work today (see more on the official website of KFU: https://kpfu.ru/philology-culture/filologiya-12111241m-m1241d1241niyatara-415645.html).

---

On February 21, an extended meeting of the Russian Academy of Education "Unity and Diversity of the Languages of the Peoples of the Russian Federation" was held. It was dedicated to the Day of the Native Language and the Year of the Cultural Heritage of the Peoples of Russia.

At the event, heads of institutions, scholars and specialists from different republics of Russia spoke about the preservation, development, study and transmission of languages to future generations, about the impact of multilingualism on the native language proficiency in the context of multiculturalism.

Radif Rifkatovich Zamaletdinov, the Director of the Institute of Philology and Intercultural Communication of KFU, Doctor of Philology, Professor, Member of the Presidium of the Council for the Russian Language under the President of the Russian Federation, Head of the Center for Native Languages and Cultures of the Peoples of the Russian Federation RAS, took part in the meeting and made a speech on the preservation and development of languages and cultures in the context of globalization.

In general, it was an effective and fruitful discussion, aimed at identifying the methodological foundations, the possibilities of individual methods and techniques of teaching native languages, which are among the most pressing issues in the work of linguists, researchers, methodologists, experts and heads of institutions (see more details on the official website KFU: https://kpfu.ru/philology-culture/halykara-tugan-tel-k1257ne-415703.html).

---

On February 21, a round table was held on topical issues of Tatar lexicography at the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The event was attended by the researchers of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan Federal University, Naberezhnye Chelny State Pedagogical University, representatives of the scientific community of the Republic of Bashkortostan, the State Council of the Republic of

Tatarstan, the Administration of the President of the Republic of Tatarstan, the editors of Tatarstan book publishing houses, as well as journalists of republican periodicals, teachers and translators of the executive committees of the republican regions. The dictionaries, compiled and published by scholars of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, were presented at a specially organized exhibition. Among them were: a six-volume Explanatory Dictionary of the Tatar Language, published in 2014–2021; a second edition of the same dictionary, published by the Tatar book publishing house (three volumes); a two-volume Russian-Tatar dictionary; a dictionary of difficulties of the Tatar language, orthoepy, dictionaries of phytonyms, etc. (for more details, see the official website of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan: http://www.antat.ru/tt/iyli/news/14599/).

---

On April 25–26, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan hosted the International Research and Practice Seminar “Galimdzhan Ibragimov and Tatar Studies of the $20^{th}$–$21^{st}$ Centuries”, dedicated to the $135^{th}$ anniversary of the classic of Tatar literature Galimdzhan Ibragimov. The main organizer of the event was the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov AS RT.

The seminar was attended by the scholars from Kazan, Ufa, Izhevsk, Yakutsk, Moscow, as well as from Kazakhstan, Kyrgyzstan, Azerbaijan and Turkey, representatives of academic institutions, universities, creative intelligentsia, including those who came to Tatarstan to take part in the events dedicated to 100 anniversary of the magazine “Kazan utlary” (for more details, see the official website of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/14903/).

---

On May 13–14, the $11^{th}$ International Turkological Conference “Islam in Russia: History, Culture, Economics” was opened in Yelabuga. The conference participants came from seven countries: Kyrgyzstan, Uzbekistan, Azerbaijan, Turkmenistan, Turkey, Kazakhstan and Russia, a total of 97 reports were submitted (for more details, see the official website of Kazan Federal University: https://kpfu.ru/elabuga/turkology/novosti /v-elabuzhskom-institute-kfu-nachalas-xi-418404.html).

---

On May 19-21, the Kazan City Hall hosted the $13^{th}$ International Economic Summit “Russia-Islamic World: KazanSummit 2022”, at which the participants discussed the specifics of the common civil identity formation as the foundation for the nation-building of modern states, contextualized the developments in the preservation of ethno-cultural diversity and suggested relevant solutions and proposals in the context of the global development trends, based on domestic and foreign experience in building a dialogue among civilizations. The event was attended by representatives of 75 countries and 27 ambassadors (for more details, see the official website of the summit: https://kazansummit.ru/?).

---

On May 21, ceremonial events, dedicated to the $1100^{th}$ anniversary of the adoption of Islam by the Volga Bulgaria, were held in Bolgar. The events were attended by more than 20 thousand people. The Bulgar Academy hosted a meeting of the organizing committee, headed by Marat Khusnullin. the Deputy Prime Minister of Russia. The participants discussed the preparation and holding of the $1100^{th}$ anniversary celebrations. Under the leadership of Ravil Gainetdin, the Spiritual Board of Muslims organized a round table called “On the lands of the Temnikovsky Murzas: The Muslim heritage of Western Mordovia”, timed to coincide with the $1100^{th}$ anniversary of the adoption of Islam by the peoples of the Volga Bulgaria and the publication of the book “Temnikov: The Fortress of Empires”. The authors of the book are Renat Abyanov, the Head of the Department of Culture at the Spiritual Administration of Muslims of the Russian Federation, and Marat Safarov, a political observer of the radio station “Vesti FM” at the All-Russian State Television and Radio Broadcasting Company (see more on the official website of the Bulgarsky Reserve: http://spas-rt.ru/news/bolgarskiy-muzey-zapovednik/programma-prazdnika-izge-bolgar-yeny-2022).

---

On June 28, the Sh. Marjani Institute of History held the Interregional Research and Practice Conference "The Contribution of the Tatar Enlighteners to the Development of Science and Education of the Turkic Peoples of the USSR (in the 1920s–30s)", dedicated to the $135^{th}$ anniversary of the famous Tatar historian, orientalist, writer, teacher and public figure Gaziz Salikhovich Gubaidullin (1887–1937) (for more details see: http://tatar studies.rf/news/742).

*The information was submitted by G. A. Nabiullina, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University.*

# 2022 ЕЛНЫҢ I ЯРТЫСЫНДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

2022 нче елның 11 нче февралендә ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты «Татарларның урта гасыр тарихына кагылышлы госманлы чыганакларын өйрәнү перспективалары» дигән темага халыкара түгәрәк өстәл уздырды. Әлеге фәнни чарада И. В. Зайцев (Мәскәү), Ильяс Кемалоглу (Истанбул, Төркия), И. М. Миргалиев, Д. М. Исхаков, И. А. Мөстәкыймов, И. Л. Измайлов, М. М. Гибатдинов, А. А. Зәбиров (Казан) кебек күренекле тарихчы галимнәр катнашты. Чыгыш ясаучылар күтәргән проблемалар түгәрәк өстәлдә катнашучыларда зур кызыксыну һәм яңа фикерләр уятты, чара бик җанлы узды. (Тулырак мәгълүматны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең рәсми сайтында карагыз: http://ft.antat.ru/uploads/805046256cf596e392-ФТ-2022-1_(1)-184-190.pd).

---

19 нчы февральдә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында быел алтынчы тапкыр «Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә алмашу мәйданчыгы» дигән халыкара фәнни-методик онлайн семинар үткәрелде.

Фәнни-методик онлайн-семинарны Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе, КФУ ИФМКның Каюм Насыйри институты оештырды. Чара шулай ук Эгей университеты (Төркия Республикасы), Фрайбург университеты (Германия), Әзербайҗан дәүләт педагогика университеты (Әзербайҗан Республикасы), Евразия милли университеты (Казахстан Республикасы), Үзбәкстанның Мирзо Улугбек исемендәге Үзбәкстан Милли университеты (Үзбәкстан Республикасы), Тау-Алтай дәүләт университеты, Башкорт дәүләт педагогика университеты һәм И. Н.Ульянов исемендәге Чуаш дәүләт университеты галимнәре катнашында үткәрелде. Семинар эшендә катнашу өчен, вуз һәм ссуз укытучылары, туган һәм чит телләр укытучылары, Россия, Төркия, Кытай, Әзербайҗан, Казахстан, Төркмәнстан, Үзбәкстаннан тюркологиянең актуаль проблемалары белән шөгыльләнүче аспирантлар, магистрлар һәм магистрантлар арасыннан 120дән артык гариза кабул ителде.

Чыгыш ясаучылар педагогик тәҗрибә белән уртаклаштылар, югары уку йортларында һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә тел белеме һәм тюркологик белем бирүнең методик проблемаларын хәл итү юлларын ачык күрсәтеп, семинарда катнашучыларның сорауларына җавап бирделәр. (Тулырак мәгълүматны Казан федераль университетының ИФМК сайтында карагыз: https://kpfu.ru/philology-culture/vi-mezhdunarodnyj-nauchno-metodicheskij-onlajn.html).

---

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татар шагыйре Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган өч томлы басманы тәкъдим итте.

Филология фәннәре кандидаты Марсель Ибраһимов сүзләренә караганда, басма документаль материалның төрлелеге белән аерылып тора. «Биредә архив чыганаклары, хатлар, көндәлекләр, истәлекләр, газета-журналлардан материаллар, төрле оешмаларның рәсми документлары бар. Болар барысы да Тукай узган тормыш һәм иҗади юлны, ул чорның милли-мәдәни мохите белән бәйле рәвештә, күрү мөмкинлеге бирә», – диде галим. (Тулырак мәгълүматны tatar-inform.ru сайтында карагыз: https://www.tatar-inform.ru/news/iyali-predstavil-novyi-trextomnik-o-tukae-5848011).

---

21 нче февраль көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында унөченче тапкыр «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Бу чара Халыкара туган тел көненә багышланган иде. Конференция гибрид формада узды. Анда Татарстан, Башкортостан, Төмән өлкәсе, Якутия, Мәскәү шәһәреннән, шулай ук Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кытай, Карелия, Сирия дәүләтләреннән дә студентлар, магистрлар һәм мәктәп укучылары катнашты.

Конференция кысаларында берничә фәнни секция һәм түгәрәк өстәлләр эшләде. Шуларның иң кызыклысы, мөгаен, филология фәннәре кандидаты, татар әдәбияты кафедрасы доценты Миләүшә Хәбетдинованың татар теле укытучылары белән «Мәктәптә Һади Такташның иҗади мирасын өйрәнү: хәзерге торышы һәм перспективалары» дигән темага оештырган чара булгандыр. Әлеге чараның шәрәфле кунаклары – АКШта яшәп иҗат итүче композитор, Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе» буенча иҗат ителгән ораториясе авторы Мәсгудә Шәмсетдинова һәм Татарстанның халык артисткасы Гөлзада Сафиуллина булды. Түгәрәк өстәлдә катнашучылар Такташ һәм музыка, Такташ шигъриятенең симфонизмы, татар теле аһәңлелеге, бөек шагыйрь иҗатының бүгенге көндә актуальлеге хакында фикер алыштылар. (Тулырак мәгълүматны КФУның рәсми сайтында карагыз: https://kpfu.ru/philology-culture/filologiya-12111241m-m1241d1241niyatara-415645.html).

---

21 нче февральдә Россия мәгариф академиясенең Туган тел көне һәм Россия халыкларының мәдәни мирас елына багышланган «Россия Федерациясе халыкларының телләр бердәмлеге һәм төрлелеге» дигән киңәйтелгән утырышы булып узды.

Әлеге чарада Россиянең төрле республикаларыннан җитәкчеләр, галимнәр, белгечләр телләрне саклау, үстерү, өйрәнү һәм киләчәк буыннарга тапшыру турында сүз алып бардылар, күпмәдәниятлелек шартларында берничә тел үзләштерүнең туган телгә йогынтысы хакында сөйләштеләр.

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Рус теле буенча Совет Президиумы әгъзасы, РАО Россия Федерациясе халыкларының туган телләре һәм мәдәниятләре үзәге җитәкчесе Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов әлеге утырышта катнашып, глобальләшү шартларында телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү хакында чыгыш ясады.

Гомумән, тел галимнәре, фәнни хезмәткәрләр, методистлар, экспертлар һәм җитәкчеләребезнең вәзгыятьтә үзәккә алынып тикшерелә торган проблемалардан саналган туган телләрне укытуның методологик нигезләрен, аерым алым һәм ысулларының мөмкинлекләрен ачыклауга йөз тоткан әлеге түгәрәк өстәл нәтиҗәле һәм файдалы үтте. (Тулырак мәгълүматны КФУның рәсми сайтында карагыз: https://kpfu.ru/philology-culture/halykara-tugan-tel-k1257ne-415703.html).

---

21 нче февральдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан татар лексикографиясенең актуаль проблемаларына багышланган түгәрәк өстәл уздырылды. Чарада Татарстан Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты галимнәре, Башкортстан Республикасы фәнни җәмәгатьчелеге, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты вәкилләре, Татарстан китап нәшрияты мөхәррирләре, шулай ук республика вакытлы матбугат басмалары журналистлары, укытучылар, республика районнары башкарма комитетлары тәрҗемәчеләре катнашты. Махсус оештырылган күргәзмәдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төзелгән һәм бастырылган сүзлекләр тәкъдим ителде. Алар арасында 2014 – 2021 елларда дөнья күргән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»; шул ук сүзлекнең Татарстан китап нәшриятында чыккан икенче басмасы (өч том); ике томлык русча-татарча сүзлек; татар теленең кыенлыклар сүзлеге, орфоэпия, фитонимнар сүзлекләре һ.б. аерым урын алды. (Тулырак мәгълүматны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең рәсми сайтында карагыз: http://www.antat.ru/tt/iyli/news/14599/).

---

25-26 нче апрель көннәрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышланган «Галимҗан Ибраһимов һәм XX–XXI гасыр татар белеме» халыкара фәнни-гамәли семинары узды. Чараны ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды.

Семинар эшендә Казан, Уфа, Ижевск, Якутск, Мәскәү, шулай ук Казахстан, Кыргызстан, Әзербайҗан, Төркия галимнәре, академик структуралар, вузлар, иҗат вәкилләре, шул исәптән «Казан утлары» журналының 100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында Татарстанга килгән галимнәр катнашты. (Тулырак Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең рәсми сайтында карагыз: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/14903/).

---

13-14 майда Алабугада «Россиядә Ислам: тарих, мәдәният, икътисад» дип аталган XI халыкара тюркология конференциясе узды. Конференциядә катнашучыларның географиясе 7 ил: Кыргызстан, Үзбәкстан, Әзербайҗан, Төркмәнстан, Төркия, Казахстан һәм Россияне үз эченә алып, барлыгы 97 доклад тәкъдим ителгән. (Тулырак мәгълүматны Казан федераль университетының рәсми сайтында карагыз: https://kpfu.ru/elabuga/turkology/novosti/v-elabuzhskom-institute-kfu-nachalas-xi-418404.html).

---

19-21 майда Казан Ратушасында «Россия–Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты узды. Анда заманча дәүләтләрнең милли төзелеше нигезе буларак гомумхалык тәңгәллеген формалаштыру үзенчәлеге турында фикер алыштылар; этномәдәният күптөрлелеген саклау буенча эшләнмәләрне анализладылар, шулай ук, цивилизацияләр диалогын булдыруның илебез һәм чит ил тәҗрибәсен исәпкә алып, глобаль үсеш трендлары контекстында актуаль карарлар һәм тәкъдимнәр турында фикер алыштылар. Чарада 75 илдән вәкилләр һәм 27 илче катнашты. (Тулырак мәгълүматны саммитның рәсми сайтында карагыз: https://kazansummit.ru/?).

---

21 май көнне Болгарда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар узды. Чарада 20 меңнән артык кеше катнашты. Болгар академиясендә Россия Хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин җитәкчелегендә 1100 еллыкны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты утырышы узды. Равил Гайнетдин җитәкчелегендәге Мөселманнарның Диния нәзарәте Идел буе Болгары халыклары тарафыннан Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгына һәм «Темников: империяләрнең ныклыгы»китабы чыгуга багышланган «Темников морзалары җирләрендә: көнбатыш Мордовиянең мөселман мирасы «дигән темага түгәрәк өстәл үткәрде. Китапның авторлары - РФ Диния нәзарәтенең мәдәният департаменты җитәкчесе Ренат Абянов һәм педагогика фәннәре кандидаты, ВГТРК «Вести ФМ» радиостанциясенең сәяси күзәтүчесе Марат Сәфәров**.** (Тулырак мәгълүматны Болгар тыюлыгының рәсми сайтында карагыз: http://spas-rt.ru/news/bolgarskiy-muzey-zapovednik/programma-prazdnika-izge-bolgar-yeny-2022).

---

28 июнь көнне Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татар мәгърифәтчеләренең СССР төрки халыкларының фән һәм мәгарифен үстерүгә керткән өлеше (1920-30 еллар)» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Ул танылган татар галим-тарихчы, көнчыгышны өйрәнүче, язучы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Газиз Салих улы Гобәйдуллинның тууына 135 ел тулуга (1887-1937) багышланган иде. (Тулырак мәгълүматны http://татаровед.рф/news/742 сайтында карагыз).

*Материаллар филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты Г. Ә. Нәбиуллина тарафыннан тупланды һәм әзерләнде.*

# ПРОШЕДШИЕ СОБЫТИЯ I ПОЛОВИНЫ 2022 ГОДА

11 февраля 2022 года Институт истории имени Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан провел международный круглый стол на тему «Перспективы изучения османских источников по средневековой истории татар». В мероприятии приняли участие такие известные ученые-историки, как И. В. Зайцев (Москва), Ильяс Кемалоглу (Стамбул, Турция), И. М. Миргалиев, Д. М. Исхаков, И. А. Мустакимов, И. Л. Измайлов, М. М. Гибатдинов, А. А. Забиров (Казань). Проблемы, поднятые выступающими, вызвали большой интерес и отклик у участников круглого стола, мероприятие прошло очень оживленно (см. подробнее на официальном сайте: http://ft.antat.ru/uploads/805046256cf596e392-ФТ-2022-1_(1)-184-190.pd).

---

18 февраля на базе ИФМК КФУ был проведен Международный научно-методический онлайн-семинар «Совершенствование методики обучения языкам: площадка обмена прогрессивной практикой», который в этом году организуется в шестой раз.

Организатором Международного научно-методического онлайн-семинара являются Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая и Институт Каюма Насыри ИФМК КФУ. Семинар организован также при участии ученых из Эгейского университета (Республика Турция), Фрайбургского университета (Германия), Азербайджанского государственного педагогического университета (Республика Азербайджан), Евразийского национального университета им. Л. Н. Гумилева и Казахского национального педагогического университета имени Абая (Республика Казахстан), Национального университета Узбекистана имени Мирзо Улугбека (Республика Узбекистан), Горно-Алтайского государственного университета, Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы, Чувашского государственного университета имени И. Н. Ульянова и других вузов. Для участия в работе семинара было принято более 120 заявок от преподавателей вузов и ссузов, учителей родных и иностранных языков общеобразовательных учебных учреждений, аспирантов, магистров и магистрантов, занимающихся проблемами обучения и изучения языков, актуальными проблемами тюркологии, из России, Турции, Китая, Азербайджана, Казахстана, Туркменистана, Узбекистана.

Выступающие делились передовым педагогических опытом, наглядно демонстрируя пути решения методических проблем языкового образования и тюркологического образования в вузах и общеобразовательных учреждениях, отвечали на вопросы участников семинара (см. подробнее на сайте ИФМК Казанского федерального университета: https://kpfu.ru/philology-culture/vi-mezhdunarodnyj-nauchno-metodicheskij-onlajn.html).

---

Институт языка, литературы и искусства АН РТ презентовал трехтомное издание, посвященное жизни и творчеству татарского поэта Габдуллы Тукая.

По словам кандидата филологических наук Марселя Ибрагимова, издание отличается разнообразием документального материала. «Здесь архивные источники, письма, дневники, воспоминания, материалы из газет и журналов, официальные документы различных организаций. Все это дает возможность увидеть пройденный Тукаем жизненный и творческий путь в связи с национально-культурной средой того времени», – сказал ученый (см. подробнее на сайте tatar-inform.ru: https://www.tatar-inform.ru/news/iyali-predstavil-novyi-trextomnik-o-tukae-5848011).

---

21 февраля в Институте филологии и межкультурной коммуникации КФУ состоялась тринадцатая международная научно-практическая конференция «Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы». Мероприятие было посвящено Международному дню родного языка. Конференция прошла в гибридной форме. В ней приняли участие студенты, магистры и школьники из Татарстана, Башкортостана, Тюменской области, Якутии, г. Москвы, а также из Казахстана, Туркменистана, Узбекистана, Китая, Карелии, Сирии.

В рамках конференции было организовано несколько научных секций и круглых столов. Самым интересным из них стало мероприятие, организованное кандидатом филологических наук, доцентом кафедры татарской литературы Миляушой Хабутдиновой с преподавателями татарского языка на тему «Изучение творческого наследия Хади Такташа в школе: настоящее состояние и перспективы». Почетными гостями мероприятия стали проживающая в США композитор, автор оратории Х. Такташа «Трагедия сынов Земли» Масгуда Шамсутдинова и народная артистка Татарстана Гульзада Сафиуллина. Участники круглого стола обсудили творчество Такташа и музыку, симфонизм поэзии Такташа, самобытность татарского языка, актуальность творчества великого поэта на сегодняшний день (см. подробнее на официальном сайте КФУ: https://kpfu.ru/philology-culture/filologiya-12111241m-m1241d1241niyatara-415645.html).

---

21 февраля состоялось расширенное заседание Российской академии образования «Единство и разнообразие языков народов Российской Федерации», посвященное Дню родного языка и Году культурного наследия народов России.

На мероприятии руководители, ученые, специалисты из разных республик России говорили о сохранении, развитии, изучении и передаче языков будущим поколениям, о влиянии освоения нескольких языков на родной язык в условиях мультикультурализма.

Директор Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ, доктор филологических наук, профессор, член президиума Совета при Президенте Российской Федерации по русскому языку, руководитель Центра родных языков и культур народов Российской Федерации РАО Радиф Рифкатович Замалетдинов принял участие в заседании и выступил с докладом о сохранении и развитии языков и культур в условиях глобализации.

В целом круглый стол, нацеленный на выявление методологических основ, возможностей отдельных методов и приемов преподавания родных языков, являющихся одной из наиболее обсуждаемых проблем в работе языковедов, научных работников, методистов, экспертов и руководителей, прошел эффективно и плодотворно (см. подробнее на официальном сайте КФУ: https://kpfu.ru/philology-culture/halykara-tugan-tel-k1257ne-415703.html).

---

21 февраля в Академии наук Республики Татарстан Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова был проведен круглый стол, посвященный актуальным проблемам татарской лексикографии. В мероприятии приняли участие ученые Академии наук Республики Татарстан, Казанского федерального университета, Набережночелнинского государственного педагогического университета, представители научного сообщества республики Башкортостан, Государственного Совета Республики Татарстан, Аппарата Президента Республики Татарстан, редакторы татарстанских книжных издательств, а также журналисты республиканских периодических печатных изданий, преподаватели, переводчики исполкомов районов республики. На специально организованной выставке были представлены словари, составленные и изданные учеными Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. Среди них шеститомный «Толковый словарь татарского языка», вышедший в 2014–2021 годах, второе издание этого же словаря, вышедшее в Татарском книжном издательстве (три тома), двухтомный русско-татарский словарь, словарь трудностей татарского языка, орфоэпия, словари фитонимов и др. (см. подробнее на официальном сайте Академии наук РТ: http://www.antat.ru/tt/iyli/news/14599/).

---

25–26 апреля в Академии наук Республики Татарстан проходил Международный научно-практический семинар «Галимджан Ибрагимов и татароведение XX–XXI веков», посвященный 135-летию со дня рождения классика татарской литературы Галимджана Ибрагимова. Основным организатором мероприятия выступил Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ.

В работе семинара приняли участие ученые из Казани, Уфы, Ижевска, Якутска, Москвы, а также из Казахстана, Киргизии, Азербайджана, Турции, представители академических структур, вузов, творческой интеллигенции, в том числе приехавшие в Татарстан в рамках мероприятий,

приуроченных к 100-летию журнала «Казан утлары» (см. подробнее на официальном сайте Академии наук Республики Татарстан: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/14903/).

---

13–14 мая в Елабуге состоялось открытие XI Международной тюркологической конференции «Ислам в России: история, культура, экономика». География участников конференции охватила 7 стран: Кыргызстан, Узбекистан, Азербайджан, Туркменистан, Турцию, Казахстан и Россию, всего было заявлено 97 докладов (см. подробнее на официальном сайте Казанского федерального университета: https://kpfu.ru/elabuga/turkology/novosti/v-elabuzhskom-institute-kfu-nachalas-xi-418404.html).

---

19–21 мая в Казанской Ратуше прошел XIII Международный экономический саммит «Россия–Исламский мир: KazanSummit 2022», на котором обсудили специфику формирования общегражданской идентичности как фундамента национального строительства современных государств; контекстуализировали наработки по сохранению этнокультурного многообразия, а также обсудили актуальные решения и предложения в контексте трендов глобального развития с учетом отечественного и зарубежного опыта выстраивания диалога цивилизаций. В мероприятии приняли представители 75 стран и 27 послов (см. подробнее на официальном сайте саммита https://kazansummit.ru/?).

---

21 мая в Болгаре прошли торжественные мероприятия, посвященные 1100-летию принятия Ислама Волжской Булгарией. Мероприятие посетили более 20 тысяч человек. В стенах Булгарской академии состоялось заседание оргкомитета по подготовке и проведению празднования 1100-летия под руководством заместителя председателя правительства России Марата Хуснуллина. Духовное управление мусульман под руководством Равиля Гайнетдина организовало Круглый стол «На землях темниковских мурз: мусульманское наследие западной Мордовии», приуроченный к 1100-летию принятия Ислама народами Волжской Булгарии и выходу книги «Темников: крепость империй». Авторы книги – к руководитель департамента культуры ДУМ РФ Ренат Абянов и кандидат педагогических наук, политический обозреватель радиостанции «Вести ФМ» на ВГТРК Марат Сафаров (см. подробнее на официальном сайте Булгарского заповедника http://spas-rt.ru/news/bolgarskiy-muzey-zapovednik/programma-prazdnika-izge-bolgar-yeny-2022).

---

28 июня в Институте истории им. Ш. Марджани состоялась Межрегиональная научно-практическая конференция «Вклад татарских просветителей в развитие науки и просвещения тюркских народов СССР (1920–30-е гг.)», приуроченная к 135-летию со дня рождения известного татарского ученого-историка, востоковеда, писателя, педагога и общественного деятеля Газиза Салиховича Губайдуллина (1887–1937) (см. подробнее на сайте http://татаровед.рф/news/742).

*Материалы подготовлены доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета Г. А. Набиуллиной.*